**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының кайбер указларын һәм Татарстан Республикасы Рәисенең кайбер указларын үз көчен югалткан дип тану турында**

«Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 15 октябрендәге 375-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителү белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясе формалаштыру тәртибе турында» 2018 елның 5 апрелендәге ПУ-285 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясе төзү турында» 2018 елның 3 маендагы ПУ-346 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 24 гыйнварындагы ПУ-21 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясе төзү турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 1 февралендәге ПУ-71 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 8 октябрендәге ПУ-724 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасы Президентының «Күпфатирлы йортларга идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясе формалаштыру тәртибе турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 12 апрелендәге 232 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасы Президентының «Күпфатирлы йортларга идарә итү эшчәнлеген лицензияләү

буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясе формалаштыру тәртибе турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 25 маендагы 330 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Рәисенең «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясе составына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 27 февралендәге 151 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Рәисенең «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясе составына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 28 декабрендәге 1034 номерлы Указы.

2. Әлеге Указ 2026 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2026 ел, 20 март
№ 218